КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 март г.Казань № 198

Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасы турында

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «2021 елда Россия Федерациясенең аерым субъектларында Чит кеше каравына мохтаҗ булган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасының бертип моделен тормышка ашыру турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 667 номерлы боерыгы белән расланган Чит кеше каравына мохтаҗ булган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасының бертип моделен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турындагы нигезләмәне;

2021 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге граждsuccessnar һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 28 гыйнвар, 32 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын

оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 2 март, 161 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән расланган 2019 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында 2020 ел, 17 апрель, 303 нче;

«Татарстан Республикасы Министр-лар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 3 сентябрь, 787 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән расланган 2020 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында» 2020 ел, 22 сентябрь, 854 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында» 2019 ел, 23 май, 432 нче карары белән расланган 2020 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында» 2020 ел, 5 декабрь, 1096 нчы.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин